| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА КУРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |
|---|---|


Ул. Центральная, д.25, с. Куралово, 422581

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы, 422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.02.2019 с. Куралово 06

**«Куралово» МУП Уставына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законга, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008 елдагы 273-ФЗ номерлы федераль законга таянып, Югары Ослан муниципаль район Советының 2018 елның 5 июлендә кабул ителгән 35-390 номерлы «Учреждение (оешма, предприятие) җитәкчесе, аны гамәлгә куючы-җирле үзидарә органы, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында» караны үтәү йөзеннән, Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Куралово» МУП Уставына түбәндәге эчтәлекле 8 өлешне өстәргә:

**8. «Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу»**

«Мәнфәгатьләр каршылыгы астында предприятие хезмәткәренең шәхси кызыксынуы аның хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясарга мөмкин һәм предприятие хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм хокуклары арасында, предприятиенең законлы мәнфәгатьләре һәм предприятие хезмәткәре тарафыннан ул милек һәм (яки) эшлекле репутациясенә зыян китерергә сәләтле

булган предприятиенеӊ законлы мәнфәгатьләре арасында каршылыклар барлыкка килергә мөмкин булган хәл аӊлашыла.

Предприятие хезмәткәренеӊ хезмәт бурычларын тиешенчә башкаруына йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы дигәндә, предприятие хезмәткәре тарафыннан акча, кыйммәтле әйберләр, башка мөлкәт, шул исәптән милек хокуклары, яки үзе өчен яки өченче затлар өчен мөлкәти характердагы хезмәт күрсәтүләр рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аӊлашыла.

Предприятие җитәкчесе (директоры) Эш бирүчегә (гамәлгә куючыга) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш.

Предприятие хезмәткәре предприятие җитәкчесенә (директорына) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә ул мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш. Предприятие җитәкчесенә (директорына) хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм хәбәрләрне теркәү тәртибе предприятие җитәкчесе (директоры) тарафыннан билгеләнә».

2. «Куралово» муниципаль унитар предприятиесе директорына предприятие уставына законнарда билгеләнгән үзгәрешләрне теркәргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

**Куралово авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Т.Ю.Тимиряева**